Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Урта Чаллы торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елның 16 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Урта Чаллы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Урта Чаллы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатынынан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны:
   – янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын төзү, ремонтлау;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Урта Чаллы торак пунктында гражданнар Җыенының 2023 елның 11 ноябрендәге 3 номерлы карары буенча җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерүгә җыелган 180 000 сум күләмендәге үзара салым акчаларын янгынга каршы резервуарлар (янгын сулыклары), янгын пирслары төзүгә, ремонтлауга юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов